Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Сәрән авыл Советы

# КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел №104

Әлмәт муниципаль районының Сәрән авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Сәрән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 80 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Сәрән авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 80 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (2018 елның 5 декабрендәге 84 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 54 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 59 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 96 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Сәрән
авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 167 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 18 607 |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 19 173 |
| Башлык урынбасары | 13 991 |

2. Әлеге карарны Чуваш Сәрәне авылы, Үзәк урамы, 34а йорт, Рус Сәрәне авылы, Үзәк урам, 15а йорт, Кителга авылы, Совет урамы, 8а йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сәрән авыл
җирлеге башлыгы

Д.А.Севастьянов